ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

10.02.2023_ Казан ш. ________43-од___

Татарстан Республикасы муниципаль архивларының ярдәм алуына ел саен үткәрелә торган конкурс турында

Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын исәпкә алуның, туплауның, сакланышын һәм файдалануны тәэмин итүнең сыйфатын алдынгы архив технологияләрен кертү һәм заманча җиһазлар һәм техниканы үзләштерү хисабына арттыруны стимуллаштыру, архив өлкәсендә югары нәтиҗәләргә ирешүне тотрыклы тәэмин итә торган муниципаль архивларга ярдәм итү, муниципаль берәмлекләрдә архив эшен оештыру, муниципаль архивлар җитәкчеләрен һәм хезмәткәрләрен һөнәри үстерү өлешендә уңай эш тәҗрибәсен тарату максатларында боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы муниципаль архивларының ярдәм алуына ел саен үткәрелә торган конкурс турында нигезләмәне расларга.
2. Архив эшен үстерү һәм мәгълүмат бирү хезмәтләрен күрсәтүне оештыру бүлегенә конкурсның оештыру-методик ягын тәэмин итәргә.
3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт
комитетының
10.02.2023 № 43-од
боерыгы белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ АРХИВЛАРЫНЫҢ ЯРДӘМ АЛУЫНА ЕЛ САЕН ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН КОНКУРС ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы муниципаль архивларының ярдәм алуына ел саен үткәрелә торган конкурс (алга таба – конкурс) турында әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2025 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 – 2025 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

Конкурсны гамәлгә куючы – ярдәм күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты.

Гариза бирүчеләр – Татарстан Республикасы муниципаль архивлары.

Ярдәм алуга конкурста катнашучылар ярдәмгә дәгъва итүчеләр була.

Ярдәм алучы – әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган, конкурс сайлап алуын узган һәм әлеге Нигезләмәнең 1.6 пунктында каралган «Россия Федерациясе Архив фонды һәм башка архив документлары сакланышын тәэмин итү проектларына ярдәм итү» номинациясендә 1 алып 7 кадәрге урынны һәм/яки «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын популярлаштыру һәм файдалану проектларына ярдәм» номинациясендә 1 алып 4 кадәрге урынны һәм/яки «Татарстан Республикасы Архив фондын Татарстан тарихы буенча аудиовизуаль документлар белән тулылыландыру проектларына ярдәм» номинациясендә 1 алып 4 кадәрге урынны алган Татарстан Республикасы муниципаль архивы.

Ярдәм – әлеге Нигезләмәнең 1.6 пунктында күрсәтелгән җиһазларны һәм техниканы муниципаль берәмлекләрдә архив эшен үстерүгә юнәлдерелгән һәм конкурсны гамәлгә куючы тарафыннан тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына (алга таба – ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты)

расланган бюджет йөкләмәләре чикләрендә сатып алынган чараларны гамәлгә ашыру өчен бер тапкыр була торган торган тапшыру.

Җиһазлар һәм техника ярдәм алучыларга Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы күрсәтмәсе нигезендә тапшырыла.

1.2. Конкурс гавами һәм, архив эше өлкәсендәге муниципаль архивларның казанышларын исәпкә алып, ачыклык һәм коллегиальлек принципларына нигезләнеп үткәрелә.

1.3. Ярдәм алучыларны конкурс нигезендә сайлап алу (алга таба – конкурс сайлап алуы) максаты – алдынгы архив технологияләрен кертү һәм заманча җиһазлар һәм техниканы үзләштерү хисабына Россия Федерациясе Архив фонды документларын туплауны, исәпкә алуны, аларның сакланышын һәм кулланылышын стимуллаштыру, муниципаль берәмлектә архив эшен оештыру өлкәсендә уңай эш тәҗрибәсен тарату, муниципаль архивларның җитәкчеләрен һәм хезмәткәрләрен һөнәри үстерү.

1.4. Конкурс сайлап алуының бурычы – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә архив эшен үстерү өчен актуаль һәм социаль әһәмияткә ия проектларны ачыклау һәм алдынгы архив технологияләрен керткән өчен муниципаль архивларны бүләкләү.

1.5. Конкурсны үткәрү сроклары ел саен ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән раслана.

1.6. Конкурс ярдәмгә дәгъва итүчеләр тарафыннан тапшырылган проектлар арасында өч номинация буенча үткәрелә:

| Номинация исеме | Ярдәм саны | Проектларны гамәлгә ашыру юнәлешләре | 1 проектка җиһазлар комплекты |
|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе Архив фонды документлары һәм башка архив документлары сакланышын тәэмин итү проектларына ярдәм итү | 7 | Татарстан Республикасы Архив фондын саклау шартлары нормативларын тәэмин итү | Архив саклагычларын архив фондларын саклау системалары белән тәэмин итү (Мобиль стеллажлар) |
| Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын популярлаштыру һәм файдалану проектларына ярдәм итү | 4 | “Яшь архивчы мәктәбе” кысаларында архив документларын (Россия Федерациясе законнары белән файдалану чикләнгән документлардан тыш) заманча архив технологияләрен | Интерактив җиһаз (Сенсорлы экранлы мәгълүмат өстәле) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | кулланып популярлаштыру, файдалану | |
| Татарстан Республикасы Архив фондын Татарстан тарихы буенча аудиовизуаль документлар белән тулыландыру проектларына ярдәм итү | 4 | Татарстан Республикасы Архив фондын тарихи, фәнни, социаль һәм мәдәни әһәмияткә ия булган һәм Татарстан Республикасының телдән тарихын Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрендә булдырганда төшерелгән аудиовизуаль документлар белән тулыландыру | Видеокамерадан, штативтан һәм видеокамера, фотоаппарат өчен тышлык-савыттан гыйбарәт комплект |

1.7. Дәгъва итүчеләр әлеге Нигезләмәдә каралган барлык тәкъдим ителгән номинацияләр буенча проектларны (һәр номинациядә иң күбе берәр) бергә тапшырырга хокуклы.

1.8. Проектлар берничә номинация буенча тапшырылганда, һәр номинация буенча аерым гариза бирелә.

1.9. Проектта проблеманың асылы, проектның максатлары һәм бурычлары, проектны гамәлгә ашыру сроклары (кимендә 3 ел) һәм урыны, төп чараларның тасвирламасы, эш күләме, көтелгән нәтиҗәләр күрсәтелергә тиеш.

1.10. Конкурсны үткәрү тәртибе, сроклары, үткәрү шартлары һәм сайлап алу критерийлары турында мәгълүмат ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына (www.http://arhiv.tatarstan.ru/) гаризаны һәм проектларны кабул итү башлануга 14 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

## II. Конкурста катнашу хокукы һәм документлар кабул итү тәртибе

2.1. Конкурста Татарстан Республикасы муниципаль архивлары катнашырга хокуклы.

2.2. Конкурста катнашу өчен түбәндәгеләр тапшырыла:

Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзаланган конкурста катнашуга гариза (әлеге Нигезләмәгә кушымта);

ярдәмгә дәгъва итүченең проект(лар)ы.

Конкурста катнашу өчен документлар Татарстан Республикасы Бердәм электрон документлар әйләнеше ведомствоара системасы аша Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе имзасы куелган хат белән бергә ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән ел саен раслана торган срокларда җибәрелә.Документлар ТР Архив эше буенча дәүләт комитетына кергән көннән алып ике эш көне эчендә теркәлергә тиеш.

2.3. Проектта аудио - һәм видеоматериаллар булган очракта, соңгылары конкурста катнашу өчен документлар ТР Архив эше буенча дәүләт комитетына тапшырылган көнне ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми электрон адресына (prm.archive@tatar.ru) җибәрелергә мөмкин.

2.4. Дәгъва итүчеләрнең документлары алар ТР Архив эше буенча дәүләт комитетында теркәлгәнннән көннән алып өч эш көне эчендә әлеге Нигезләмәнең 1.7, 1.9, 2.2 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәүгә тикшерелә.

2.5. Конкурста катнашуга кертмәү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларның әлеге Нигезләмәнең 1.7, 1.9, 2.2 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

сурәттә һәм тавышта бозыклыклар булган, шулай ук мәгълүмат бозылуга яки югалуга китерә торган башка кимчелекләре булган аудио – һәм видеоматериаллар тапшырылу;

документларның ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән ел саен раслана торган аларны тапшыру сроклары бозылып тапшырылуы.

Конкурста катнашуга кертелмәгән гариза бирүчеләр барлык кимчелекләрне бетергәннән соң конкурста катнашуга документларны аларны тапшыру өчен билгеләнгән срокта кабат тапшыра ала.

Конкурста катнашуга документлар кабул итү төгәлләнү датасыннан соң кергән документлар каралмый.

2.6. Әлеге Нигезләмәнең 2.5 пунктына ярашлы рәвештә конкурста катнашуга кертелмәгән гариза бирүчеләргә хәбәр итү гариза бирүчеләрнең әлеге Нигезләмәнең 2.2, 2.3 пунктларында күрсәтелгән документларының Татарстан Республикасы Бердәм электрон документлар әйләнеше ведомствоара системасы аша ТР Архив эше буенча дәүләт комитетында теркәлгән көненнән алып өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

## III. Проектларны гавами яклау тәртибе

3.1. Проектларны гавами яклау вакыты, урыны һәм графигы ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының ел саен чыгарыла торган боерыгы белән билгеләнә һәм

гариза бирүчеләргә ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының ел саен чыгарыла торган боерыгында күрсәтелгән гавами яклауның беренче датасына кадәрге җиде эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән хәбәр ителә.

3.2. Проектны гавами яклау муниципаль архив җитәкчесе яки башка вәкаләтле зат тарафыннан башкарыла.

3.3. Бер проектны гавами яклауга иң күбе 10 минут вакыт бирелә.

## IV. Экспертлар советын төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибе

4.1. Конкурска тапшырылган проектларга эксперт бәяләвен гамәлгә ашыру һәм җиңүчеләрне билгеләү өчен Экспертлар советы төзелә.

4.2. Экспертлар советы тугыз кешедән гыйбарәт архив эше белгечләреннән, җәмәгатьчелек вәкилләреннән Экспертлар советы рәисе, рәис урынбасары, җаваплы сәркатибе һәм әгъзалары составында төзелә.

4.3. Сәркатиб конкурсны оештыру-техник ягын тәэмин итү эшләрен башкара һәм тавыш бирү хокукына ия түгел.

4.4. Экспертлар советы составы ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән раслана.

4.5. Экспертлар советы эше утырышлар рәвешендә башкарыла. Экспертлар советы утырышларны рәис карары буенча үткәрә һәм алар, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

4.6. Экспертлар советы утырышларын рәис үткәрә. Ул булмаганда очракта, вазыйфалары аның урынбасарына (алга таба - рәислек итүче) йөкләнә.

## V. Конкурска тапшырылган проектларны бәяләү тәртибе һәм критерийлары

5.1. ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты ярдәмгә дәгъва итүчеләрнең проектларын танышу өчен, гавами яклауның беренче датасына кадәр унҗиде көннән дә соңга калмыйча, Эксперт советы әгъзаларына җибәрә.

5.2. Ярдәмгә дәгъва итүчеләрнең проектларын бәяләгәндә Эксперт советы тапшырылган материалларны бәяләүнең бәяләү критерийларына нигезләнгән объективлыгы тәэмин ителә.

5.3. Ярдәмгә дәгъва итүчеләрнең проектларын бәяләү Экспертлар советы әгъзалары тарафыннан, әлеге Нигезләмәнең 5.6. пунктында күрсәтелгән бәяләү критерийларына нигезләнеп, ярдәмгә дәгъва итүченең гавами яклавы үткәрелгән вакытта эксперт бәяләве алымы белән гамәлгә ашырыла.

5.4. Экспертлар советы әгъзасы һәр критерий буенча баллар куя, һәм алар кушыла.

5.5. Баллар эксперт битләренә кертелә, Экспертлар советы әгъзасы имзасы белән раслана һәм рәислек итүчегә тапшырыла.

5.6. Проектларны бәяләү критерийларына түбәндәгеләр керә:

проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте (1 алып 10 кадәр балл);

чараларны гамәлгә ашыруга программа-максатчан якын килү (1 алып 10 кадәр балл);

проектның ахыргы нәтиҗәсе күләме буенча проектның масштаблылыгы (1 алып 15 кадәр балл);

проектның методик ягы эшләнеп бетү, проектның Татарстан Республикасының башка муниципаль архивларында гамәлгә ашыру өчен тиражлана алуы (1 алып 10 кадәр балл);

проектны алга таба үстерү перспективалары булу (1 алып 15 кадәр балл).

5.7. Экспертлар советы әгъзалары тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5.6 пунктында күрсәтелгән критерийлар буенча куелган балларны кушу нәтиҗәләре буенча Экспертлар советында рәислек итүче һәм аның әгъзалары тарафыннан имзаланган ярдәмгә дәгъва итүчеләрнең йомгаклау рейтингы төзелә.

5.8. Конкурста катнашучылар җыйган баллар тигез булганда, җиңүче тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Эксперт советы тарафыннан тавышларның гади күпчелегенә нигезләнеп билгеләнә. Җыелган тавышлар саны тигез булганда Эксперт советы рәисенең тавышы хәлиткеч була.

## VI. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү һәм бүләкләү

6.1. Экспертлар советы, ярдәмгә дәгъва итүчеләр проектларны гавами яклауны тәгәлләгәннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча, йомгаклау утырышында йомгаклау рейтингына нигезләнеп кара кабул итә.

6.2. Эксперт советы карары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәне рәсмиләштерү срогы Эксперт советының йомгаклау утырышы үткәрелгән көннән алып өч эш көнен тәшкил итә.

6.3. Әлеге Нигезләмәнең 1.6 пункты нигезендә «Россия Федерациясе Архив фонды документлары һәм башка архив документлары сакланышын тәэмин итү проектларына ярдәм итү» номинациясендә 1 алып 7 кадәрге урынны алган һәм/яки «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын популярлаштыру һәм файдалану проектларына ярдәм итү» номинациясендә 1 алып 4 кадәрге урынны һәм/яки «Татарстан Республикасы Архив фондын Татарстан тарихы буенча аудиовизуаль документлар белән тулылыандыру проектларына ярдәм итү» номинациясендә 1 алып 4 кадәрге урынны алган ярдәмгә дәгъва итүчеләр конкурсның җиңүчеләре дип табыла.

6.4. Конкурста җиңгән ярдәмгә дәгъва итүчеләрнең исемлеге, Экспертлар советының йомгаклау утырышы беркетмәсенә нигезләнеп, беркетмәгә кул куелган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән раслана.

6.5. Конкурсның җиңүчеләре исемлеге боерыкка кул куелган көннән алып өч эш көне эчендә ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәсми сайтына (www.http://arhiv.tatarstan.ru/) урнаштырыла.

6.7. Конкурска тәкъдим ителгән проектлар муниципаль архив җитәкчеләренең конкурс үткәрү елыннан соң килүче елның 31 декабренә кадәр шәхси гаризасы нигезендә кире кайтарыла.

## VII. Ярдәм алучылар тарафыннан хисаплар бирү тәртибе һәм сроклары

7.1. Ярдәм алучылар 3 ел дәвамында ел саен ТР Архив эше буенча дәүләт комитетына ярдәм буларак бирелгән җиһазлардан һәм техникадан максатчан файдалану һәм хисап елыннан соң килүче елның 1 июненә кадәр эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисаплар тапшыра.

7.2. Эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисапта түбәндәге төп позицияләр ачыла:

проектны гамәлгә ашыру тасвирламасы;

«Россия Федерациясе Архив фонды документлары һәм башка архив документлары сакланышын тәэмин итү проектларына ярдәм итү» номинациясендә:

Архив саклагычларның архив саклагычның күләмен, стеллаж киштәләренең үлчәү метрларындагы озынлыгын арттырырга мөмкинлек бирә торган архив документларын саклау системалары белән җиһазлануы;

Проектны гамәлгә ашыру кысаларында саклауга кабул ителгән, шул исәптән Татарстан Республикасы Архив фонды составына кертелгән документларның саны;

«Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын популярлаштыру һәм файдалану проектларына ярдәм итү» номинациясендә:

«Яшь архивчы мәктәбе» кысаларында җаһазлардан файдаланган түбәндәге чаралар саны:

дәресләр/лекцияләр;

күргәзмәләр;

экскурсияләр;

практик дәресләр;

«Татарстан Республикасы Архив фондын Татарстан тарихы буенча аудиовизуаль документлар белән тулыландыру проектларына ярдәм итү» номинациясендә:

проектны гамәлгә ашыру кысаларында саклауга кабул ителгән һәм Татарстан Республикасы Архив фонды составына кертелгән аудиовизуаль документлар саны;

муниципаль берәмлекнең телдән тарихын төзегәндә интервью алынганнар саны;

барлык номинацияләрдә:

җәмәгатьчелек фикерен (массакүләм мәгълүмат чараларындагы хәбәрләрне, анкеталарны) күзәтү;

фото-һәм видеоматериаллар.

## VIII. Финанслау

8.1. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 – 2025 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында каралган акчалар хисабына башкарыла.

Татарстан Республикасы муниципаль архивларының ярдәм алуына ел саен үткәрелә торган конкурс турында нигезләмәгә
кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ АРХИВЛАРЫНЫҢ
ЯРДӘМ АЛУЫНА ЕЛ САЕН ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН
КОНКУРСТА КАТНАШУГА
ГАРИЗА

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Проектның исеме | |
| 2 | Номинация | |
| 3 | Муниципаль архивның тулы исеме (алга таба – учреждение) | |
| 4 | Муниципаль архив җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| 5 | Муниципаль архивның рәсми адресы | |
| 6 | Элемтә өчен телефон, e-mail | |

Татарстан Республикасы
муниципаль районы (шәһәр округы)
башкарма комитеты җитәкчесе имзасы ________________________Ф.И.А.и.
(соңгысы булган очракта)

Гариза тутыру датасы ___________________